**Презентация**

# «С.Хәким иҗатында Тукай темасы»

Эшне башкарды: Шипачева А.З.

ГАБДУЛЛА
ТУКАЙ
1886–1913



# Бөек татар шагыйре



# Сибгат Хәким (1911-1986)

**Халыктагы тере фикерләрнең**
**Хәкиме син-тугры хәкиме...**

- Тикшерү объекты: С. Хәкимнең «Пар ат», «Кырыгынчы бүлмә», «Шагыйрьнең балачагы» поэмалары һәм «Тукай дәфтәреннән» шигырьләр циклы.
- Хезмәтнең өйрәнү предметы: С. Хәкимнең шигырь һәм поэмаларында Тукай темасы.
- Безнең максатыбыз: С. Хәким иҗатында Тукай темасын өйрәнү һәм шагыйрьнең Г. Тукайга багышланган әсәрләрен мәктәптә нәтиҗәле өйрәнүнең методик алымнарын ачыклау.

# С. Хәким “Җырларымда телим”

Авыруыма врач кирәк түгел,
Йөрәгемнең беләм дәвасын.
Һәр ел саен кайтып иснәп киләм
Авылыбызның чиста һавасын.

Язар өчен илһам эзлә, диләр,
Урын эзлә диләр, ямьлерәк.
Никтер минем шигъри хисләремә
Арышларның исе тәмлерәк!

Яннарына барам агайларның,
Фикерләрен ишетеп карарга.
Җырларыма телим гомерем буе
Алар рухы белән янарга.



# Г.Тукайга һәйкәл





“Пар ат” шигыренә иллюстрация. Рәссам Б. Урманче

**...Сез күрәсез, аның тормыш юлы**
**Шактый ямьсез, шактый караңгы.**
**Мин үзем дә кайнар яшем белән**
**Катыштырып язам карамны...**
**(“Шагыйрьнең балачагы”)**






**Тукай яшәгән йорт – «Болгар». Бу йорт С. Хәким өчен изге йорт. Шагыйрь анда Тукай рухы яшәвенә ышана, коридорда Тукай адымнары ишетелә...**

С.Хәким «Тукай районына» дип юллап хатлар язганда Тукай районы булмый әле.

Андый район булмаса да җирдә,
(Гаебе юк андый хатаның),
Мин сугышта Тукай районына
Яздым хатлар – барды хатларым.




# С.Хәким иҗатын мәктәптә өйрәнү

- 5-11 нче сыйныфлар өчен Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан расланган татар урта мәктәпләре өчен әдәбият программасында 7 нче сыйныфта С. Хәким иҗатын өйрәнү өчен өч сәгать вакыт бирелә. Язучының тормыш һәм иҗат юлы турында гомуми белешмә бирү «Юксыну» , «Әнкәй», «Тегермән стенасындагы язулар» һәм «Һәйкәл урынында уйланулар» шигырьләрен өйрәнү күздә тотыла. 11 нче сыйныфта С. Хәким иҗатына гомуми күзәтү тәкъдим ителә.
- Рус телендә гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәпләре өчен татар әдәбиятыннан авторлык программасында да 7 нче сыйныфлар өчен Сибгат Хәкимнең тормыш юлы, иҗаты турында белешмә, «Бакчачылар» поэмасы, «Бу кырлар, бу үзәннәрдә» шигыре өчен ике сәгать каралган. 8 нче сыйныфта шагыйрьнең «Җырларымда телим», «Әнкәй» шигырьләрен өйрәнү планлаштырыла. Өстәмә уку өчен «Клиндерләр эзлим» шигыре тәкъдим ителә.

# Югарыда өйрәнүләребездән чыгып түбәндәге нәтиҗәләргә килдек:

- – С. Хәким татар әдәбиятында Тукай темасын иң көчле яктыртучы әдипләребезнең берсе;
- – С. Хәким иҗаты һәм Тукай иseме янәшә, ләкин ул Тукай стилендә иҗат итми;
- – шагыйрь Тукай иҗатын бик яхшы белә һәм ул үз шигырьләрендә даими рәвештә Тукай шигырьләреннән өзекләр китерә;
- – С. Хәким Тукайны мактау, аңа дан җырлау белән генә чикләнми, ә әдипнең ачы язмышын да яктырта, заманында аны юк итәргә теләүчеләрне үзенең шигырьләре аша камчылый;
- – «Пар ат» һәм «Шагыйрьнең балачагы» поэмаларында уртак бер күренешкә тап буласың: аларның икесендә дә Тукай турында шагыйрь үзе түгел, ә авторның әнисе («Пар ат»), я Тукайның Саҗидә апасы сөйли. Бу күренеш поэмаларның мөмкинлекләрен күпкә киңәйтә;
- – «Кырыгынчы бүлмә» поэмасы чын мәгънәсендә татар тарихы җирлегендә Тукай шәхесенең зурлыгын, рухи батырлыгын, фәлсәфи тирәнлектә сурәтләү аша үткәнгә мөнәсәбәтен, бүгенгегә мөрәҗәгатен белдергән, үз иҗатына карашын чагылдырган кыю фикерле лирик әсәр. Поэмада эзлекле сюжет сызыгы юк. Автор поэмада сурәтләнгән вакыйга-күренешләрне, предметларны, лирик «мин»нең уй-кичерешләрен кырыгынчы бүлмә поэтик деталь тирәсенә туплый алган. «Болгар» бүлмәсе, метафора рәвешен алып, төрле бәйләнешләр тудырырга ярдәм итә;
- - шагыйрьнең Тукайга багышланган шигырь һәм поэмалары мәктәп программасына кертелмәгән, әмма мөгаллим аны Г. Тукай иҗатын яисә 11 нче сыйныфта шагыйрь иҗатына гомуми күзәтү вакытында өйрәнә ала. С. Хәким иҗатын Тукай исеме, аның иҗаты белән бәйләп өйрәнү һәр яктан да отышлы була ала.



КАЗАН (ИДЕЛ БУЕ) ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫНЫҢ
АЛАБУГА ИНСТИТУТЫ
ПЕРМЬ КРАЕНЫҢ БАРДА РАЙОНЫ
МУНИЦИПАЛЬ БЕЛЕМ БИРҮ ИДАРӘСЕ

ИДЕЛ БУЕ ФЕДЕРАЛЬ ОКРУГЫНДА МИЛЛИ МӘГАРИФНЕ ФӘННИ-МЕТОДИК ЯКТАН ТӘЭМИН ИТҮ ПРОБЛЕМАЛАРЫ

Татар теле һәм әдәбияты укытучыларының
III Бөтенрәсәй фәнни-гамәли конференциясе материаллары
11 март 2016 ел

АЛАБУГА 2016



Казанский федеральный УНИВЕРСИТЕТ
Елабужский ИНСТИТУТ

СЕРТИФИКАТ УЧАСТНИКА

III Всероссийской научно-практической конференции
«Проблемы научно-методического обеспечения национального образования в Приволжском федеральном округе»
(Пермский край, Бардымский район, с. Березники)

ВЫДАН

Шипачевой
Альбине Загитовне
(Республика Татарстан, г. Нижнекамск)

Е.Е. Мерзон

«11» марта 2016 г.

# Игътибарыгыз өчен рәхмәт!

